# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «МӘЛӘКӘС» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«22» ноябрь 2021 ел № 17/1

**«Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 30 сентябрындагы 30/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 5, 394 һәм 397 статьялары, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 30 сентябрындагы 30/2 номерлы карарына (2017 елның 28 декабрендәге 35/2 номерлы, 2018 елның 19 сентябрындаге 45/8 номерлы, 2018 елның 09 ноябрендәгы 46/1 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 57/2 номерлы, 2020 елның 1 мартындагы 61/1 номерлы, 2021 елның 2 апрелендәге 10/1 номерлы, 2021 елның 27 августындагы 15/1 номерлы карарлар үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктка пуктча өстәргә:

«11) «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән махсус оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә карата 0,001.».

2. Әлеге карарның 1 пункты 1.1 пункты рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ю.П.Васильев